Әнәс Кари

Тамчы тамганда

Әнәс Кари

ТАМЧЫ ТАМГАНДА

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

шигырьләр



КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
1990

ББК 84 (2Р-Тат)-5
К 27

Энәс Кари
К 27 Тамчы тамганда: Шигырьләр. Казан: Татар. кит. нәшр., 1990.—32 бит.
ISBN 5—298—00168—8

Бу китапка Энәс Каринның табигать һәм хайваннар турында язылган шигырьләре кертелде.

К $\frac{4803010200-033}{М\ 132(03)-90}$ 174—90 ББК 84 (2Р-Тат)-5

ISBN 5—298—00168—8
© Татарстан китап нәшрияты, 1990

МӘКТӘП

Зур булган инде
Абыем Гата:
Көн дә мәктәптә
Ул укып кайта.

Мәктәп ул ямьле,
Бик күңелле, ди,
Һичкемнең аннан
Кайтасы килми.

Анда эти күк
Олы абый бар,
Укытучы дип
Аны атыйлар.

Балаларны ул
Сөеп укыта,
Аларга китап,
Дәфтәр тарата.

Гата абый да
Аңардан алган,
Китаплар белән
Букчасы тулган.

Иң кирәклесе
«Әлифба» икән,
Белем ачкычы
Шунсында икән.

Гата абый күк
Үскәч, үзем дә
Мәктәпкә барып
Йөрермен көн дә.

Белемле итәр
Мине ул мәктәп,
«Әлифба» дигән
Кадерле китап.

КЕЧКЕНӘ АГРОНОМ

Тышта яз әле
Яңа башлана:
Тәүге тамчылар
Түбәдән тама.

Ләкин тынгысыз
Кечкенә Зөһрә
Яз өчен күптән
Хәзерлек күрә.

Көздән түтәлләр
Казып куйды ул,
Тирес, көл — барсын
Күптән җыйды ул.

Инде тырышып
Орлыклар сайлый,
Аларны сынап,
Шыттырып карый.

Туфрак тутырган
Әрҗәләрендә
Яңа яфраклар
Ишәя көн дә.

Кечкенә Зөһрә
Куана хәзер:
Һәммә нәрсәсе
Чәчүгә әзер!

Кар бетүгә ул
Бакчада булыр,
Шалкан, кәбестә,
Кыяр утыртыр.

Аларны сөеп
Тәрбия итәр:
Җирен йомшартыр,
Утар, су сибәр.

Яшелчә аңа
Бирер мул уңыш,
Чөнки ул эшчән,
Хәстәрле, тырыш.

ҖИЛӘК ПЕШТЕ

Җиләк пеште, җиләк пеште
Безнең бакчада!
Күңел рәхәтләнеп китә
Күргән чакларда.

Кирәк түгел бал, шикәрең:
Шулкадәр татлы!
«Нилектән, дим, әби, җиләк
Тәмле бу хәтле?»

«Үстергән, караган чакта
Булыштың миңа,
Татлы булып өлгерделәр
Җиләкләр шуңа».

МИНЕМ КУНАГЫМ

Зур бер бүләк алгансыман,
Чын күңелдән куандым:
Сыерчык килде, сыерчык,
Сагынып көткән кунагым.

Хәзерләнеп тордым күптән
Каршыларга дип аны.
Әнә ничек яраткан ул
Мин ясаган ояны.

Тирәсендә очып йөргәч,
Кереп эчен карады:
Яңа өен котлагандай,
Матур итеп сайрады.

ЧЕБИЛӘР

Акыллы кыз Гөлфия
Чебиләрне бик сөя:
Әнисе эштә чагында,
Ул аларга җим сибә.

Эндәштеме: «Чеп-чеп!» — дип,
«Ачыктык шул бик-бик!» — дип,
Тирәсенә чебиләр
Җыелыша: «Чик-чик!» — дип.

Их чебиләр, чебиләр!
Һич тынычлык бирмиләр:
Гөлфиянең кул астында
Чәрелдәшеп йөриләр.

Ул аларны аралап,
Җим өләшә чамалап,
Ә чебиләрнең анасы
Читтә йөри сагалап.

Алар туйгач, кузгалырга
Дәшә тавык барсына,
Ә Гөлфия карап кала
Тимәсен дип карчыга.

ЛӘЙСӘН ЯВА

Яз иртәсен котлагандай
Матур булып,
Зәңгәр күкне каплап алды
Аксыл болыт.

Бизәкләнгән тәсле булды
Бөтен һава:
Кар өстенә шыбыр-шыбыр
Ләйсән ява.

Ләйсән, ләйсән!
Иң беренче
Язгы яңгыр!
Көчлерәк яу,
Күңелләрне
Син куандыр.

Җир өстендә яткан карлар
Эреп бетсен,
Басуларда эш кайныйсы
Көннәр җитсен.

Без чыгарбыз бакчаларга
Ул көннәрдә,
Яшелчәләр утыртырбыз
Түтәлләргә.

БЕЗ ҮСТЕРГӘН ГӨЛЛӘР

Умарталык янына
Ясадык без түтәлләр,
Җыелышып, бергәләп
Утырттык матур гөлләр.

Хәзер килеп карагыз,
Бакча нинди күңелле:
Гөлләребез хуш исле
Чәчәкләргә күмелде.

Бал кортлары биредә
Очып йөри безелдәп,
Чәчәкләрдән чәчәккә
Куна алар бал эзләп.

Бераз йөргәч очалар
Умарталык ягына,
Җыйган балны бушаткач,
Килә алар тагы да.

Куанабыз шунда без,
Бал кортлары килә дип,
Без үстергән чәчәкләр
Балны бик күп бирә дип.

ҚЫШ БАБАЙ

Яшел чыршы тирәсендә,
Җыелып бертугандай,
Әйлән-бәйлән уйный идек,
Килеп керде Кыш бабай.
  Әй, Кыш бабай, Кыш бабай,
  Хуш киләсең, уз бире;
  Шатланышып, җыр белән
  Каршылыйбыз без сине.

Ак таягың кулыңда,
Ап-ак туның кигәнсең,
Бөтен төшең бәсләнгән,
Күп җир гизгән икәнсең.
  Әй, Кыш бабай, Кыш бабай,
  Хуш киләсең, уз бире:
  Кунак булып килер дип,
  Күптән көттек без сине.

Әй, Кыш бабай, Кыш бабай,
Бик хуш килдең, уз бире.
Безне сагынып килгәнгә,
Урының булсын өй түре.
  Бәйрәмебез, син килгәч,
  Матурланды тагын да,
  Бик күңелле уйнавы
  Яшел чыршы янында.
Әй, Кыш бабай, Кыш бабай,
Безнең сөйгән кунак син,
Ямьле үтсен кичәбез,
Безне көлдер, уйнат син.

ҠОШЛАР ТУЙДЫРАМ

Җимлек ясап бирде миңа
Абыем Сәлим.
Шунда хәзер кошлар өчен
Җим сибәм мин.
Бире килә күк күгәрчен,
Песнәк, чыпчык,
Җыелалар бер-бер артлы
Пыр-пыр очып.

Ашап туйгач китә алар
Төрле якка.
Тик күгәрчен генә кала
Иң азакка.

Ул да туйган,
Биегән күк,
Уйнап йөри.
Миңа рәхмәт әйткән сыман:
«Гөлдергү»,— ди.

ЧАҢГЫ ШУАБЫЗ

Нинди матур көн
Чаңгы шуарга!
Иптәшләр белән
Чыгабыз тауга...

Тау түбәсенә
Менеп баскач та:
«Ай-яй биек!» — дип,
Карыйсың аска.

Ә без шундыйлар —
Курка белмибез,
Кала ак карда
Тик эзләребез.

Тезләр бөгелгән,
Ә куллар алда.
(Сикәлтәләрдә
Егылып калма!)

Шуабыз шулай,
Карлар туздырып,
Төшәсе килә
Беренче булып.

БОЕКМА, ПЕСИЕМ

Сөйгән песием минә
Башын түбән игән дә,
Һичнәрсәгә карамый,
Боегып утыра идәндә.

Әй, песием, кечкенәм,
Син ник болай күңелсез?
Ә мин һичбер уеннан
Ямь таба алмыйм синсез.



Яныңа килдем, әйтче:
Әллә карының ачтымы?
Әллә тоткан тычканың
Тәпиең тешләп качтымы?

Әгәр ачыккан булсаң,
Мә, сөт бирәм, яларсың,
Яларсың да туярсың,
Аннары, шәт, уйнарсың.

Качкан булса тычканың,
Аңа тәбе куярмын,
Кичен килеп эләксә,
Сине тагын сыйлармын...

Синең белән бая мин
Юкка саксыз уйнадым:
Кәгазь күсемне ерткач,
Ачуланып кыйнадым.

Шулай дигәч, сыйпагач,
Песи тагын шатланды,
Минем арттан йөгереп,
Бергә уйный башлады.

КАЗ БӘБКӘЛӘРЕ

Быел минем сөйгән казым
Унбер бәбкә чыгарды,
Өй буенда йөри әнә,
Иярткән дә шуларны.
Нинди нәни, нинди чибәр,
Сөйкемле бәбкәләре.
Кулга алып сөяр идем,
Тешләр, дим, әнкәләре.
Бәбкәләрем пипелдәшеп
Ябыштылар чирәмгә,
Үләннәрне йолкый алмый
Йөри алар тирәмдә.
Кайчагында югарыдан
Сагалап үтә тилгән.
Тик мин аларның берсен дә
Явыз тилгәнгә бирмәм.
«Әй тилегән, тилегән!
Бер бәбкәгә тилмергән,
Бер күзенә яфрак,
Бер күзенә туфрак!
Көшшү!»
Ана каз да, батырланып,
Ыслап ала тилгәнгә,
Балаларын саклый бит ул
Тилгәннән дә, миннән дә.
Мин аларны үстерермен,
Җәй үтеп, килер көз дә,
Унбер бәбкәчек урнына
Унбер каз булыр бездә.

АҚ ҚАЕН

Шомырт куаклары арасында
Сузылып үскән безнең ак каен,
Көз көнендә яфракларын коеп,
Яшел күлмәк кия яз саен.
Талгын җилдә аның бөдрәсеннән
Тәмле исләр аңкый һәр якка,
Лебердәшеп куя яфраклары...
Эх, күңелле була шул чакта!
Матурлыгын сөеп, бәрхет түшле
Қупшы кошлар куна аңарга,—
Без ял иткән чакта, матур кичне
Я иртәне котлап сайрарга.
Табигатьнең дәртләндергеч көен
Без алардан йотылып тыңлыйбыз,
Тыңлыйбыз да
Бакча яме булган
Ак каенны мактап җырлыйбыз.

БАКА

Камышлы күлдә,
Куак төбендә
Ята быгырдап
Зур башлы бака,
Батып һәм калкып,
Су дулкынлатып,
Тынмый кычкыра:
«Бака-ка-ка-ка!»

Аяз көннәрдә,
Кояш көлгәндә,
Куак төбеннән
Өскә чыга ул,
Авызын ачып,
Түмгәккә басып,
Камыш аралай
Черки куа ул...

Черкиләр тотса
Һәм ялмап йотса,
Ярсып сикерә
Мактанчык бака.

Күл сазлыгында
Ул, бата-калка,
Тагын кычкыра:
«Бака-ка-ка-ка!»

2 З-397

МАКТАНЧЫК ИЛЬЯС

Ильяс беркөн мактана:
«Кулъяулыгым ефәк,— ди,—
Күрсәтермен сезгә дә,
Андый яулык сирәк»,— ди.

Тыңлап торган иптәше,
Түзмичә бу сүзенә,
Якын килеп, Ильясның
Туры әйтте йөзенә:

«Кулъяулыгым бар, дисең,
Ник кесәңдә йөртмисең?
Борын астың юпь-юеш,
Нигә шуны сөртмисең?»

КҮБӘЛӘККӘ

Чәчәкләр күмгән бакчаны
Сөйгән урының итеп,
Очасың гөлдән гөлләргә,
Ак канатларың җилпеп.

Син куанганга куангандай
Гөл сабагы тирбәнә,
Тал тармакларын селкетеп
Былбыл сайрап җибәрә.

Гөл таҗлары арасыннан
Тирә-ягың күзлисең.
Әйтче, зинһар, мине мәллә
Бакчабыздан эзлисең?

АКБАЙ

Бик ярата Алмаз маэмаен,
Чакыра аны: «Қил, дип, Акбаем!»
Эте килә чабып янына...
(Елгырланып киткән тагы да!)
Қулына ул үреләә шул вакыт
Һәм сорый чирәмгә ятып.
Тик сыйларга дусты ашыкмый:
«Бераз гына эшләп алыйк»,— ди.
Қизәнә дә бөтен көченә
Таяк ташлый бакча эченә.
«Я, Акбаем, ыргыл, сикер,— ди,—
Таягымны табып китер»,— ди.
Маэмай, шуны көткән шикелле,
Қиртә аша ярсып сикерде.
Таякны ул табып алды да
Қабып килде Алмаз янына.
Менә дусты ипи ыргыта,
Акбай аны һавадан тота.
Рәхәтләнеп, маэмай сыйлана,
Аны сыйпап, Алмаз сөйләнә:
«Қүңелсез ул, иренеп яшәсәң,
Тәмле була, эшләп ашасаң».

ЧЫПЧЫГЫМ

Бар минем
Кошчыгым —
Кечкенә
Чыпчыгым.

Бер көнне
Салкыннан
Җиргә ул
Егылган.

Ә аны
Мин күрдем,
Бүлмәгә
Китердем.

Терелткәч
Җылытып,
Уйнадым
Очыртып.

Мин аны
Яратам —
Иркәләп
Ашатам.

Ә тиздән
Кыш бетәр,
Чәчәкле
Яз җитәр.

Без тышка
Чыгарбыз,
Бергәләп
Уйнарбыз.

САНДУГАЧ

Ямьле язны котлап,
Зур бакчада
Ак чәчәкләр аткан алмагач,
Алмагачның нечкә ботагында
Кагына-кагына сайрый сандугач.

Нәфис тавышы белән тойгыларның
Иң нәзек кылларын чиртә ул,—
Бәйрәм кебек якты яз иртәсен
Чиксез сөеп тәбрик итә ул.

Чут-чут итеп,
Баскан ботак очын
Тибрәп-тибрәп алган чагында
Таң калдыргыч матур тавышлары
Күңеллерәк яңгырый тагын да...

Үзе кебек дәртле тойгыларның
Иң нәзек кылларын чиртә ул,—
Бәйрәм кебек якты яз иртәсен
Сөеп шулай тәбрик итә ул.

ҚЕМ ЯЛҚАУ?

Җәмил әйтә
Мәчесенә:
«Ай-һай песи,
Бик ялкау син:
Сәгать буе
Қарап торам,
Селкенми дә
Тик ятасың».

Ә мәчесе
Телгә килә:
«Арганлыктан
Мин ял итәм.
Сәгать буе
Тик утыргач,
Үзең миннән
Ялкау икән».

ЧЫНЫГА, ИМЕШ...

Яталар малайлар
Соры ком өстендә.
Ялтырый тәннәре...
Бронза төсендә.

Карагыз, моңарчы
Иренгән Фазыл да
Кояшта кызына
Башкалар янында.

«Көн саен йөрмәм мин,
Шул минем сүзем,— ди;
Берничә көнлекне
Кызынам бүген»,— ди.

Аркасы янса да,
Түзә ул, сиздерми —
Күршесе алдында,
Үзенчә, сер бирми.

Ә тәне, әй, әрни,
Әй, тире әчетә.
Еламый түзәргә
Кирәк бит, ничек тә!..

«Тәнем, ник сызлыйсың,
Аркам, ник янасың?..»

ҚАРМАҚ САЛГАНДА

Яңгырдан соң йөри Рәхим
Қармак салып.
Бервакытны чиртә башлый
Шаян балык.

Рәхим каушый
Һәм кармагын
Тартып ала;
Җимне йоткан балык чыкмый,
Суда кала...

Яр буенда Рәхим шулай
Байтак йөрде,
Балыкның ул бар хәйләсен
Инде белде.

Қармагын ул ала хәзер
Вакытында,
Һәм балык чыга ялтырап
Шул чагында.

БЕЗНЕҢ СЫЕР

Безнең сыер өебезне яхшы белә.
Көтүдән ул мөгри-мөгри кайтып керә.

Әйтерсең лә: «Мине каршы алыгыз, ди,
Мул итеп сөт алып кайттым, савыгыз»,— ди.

Күптән инде ияләндем мин аңарга,
Йөгереп чыгам көн дә аны каршыларга.



ГӨЛ ЯНЫНДА

Чыккан иде Вил
Күңел ачарга,
Ал чәчәкле гөл
Күрде бакчада.

Әй, чәчәкләре
Матур бу гөлнең!..
Кулы берсенә
Сузылды Вилнең.

Ятратканын ул
Алды да өзеп,
Тагын үрелде:
Булмый бит түзеп.

Ләкин әйтте гөл:
«Кадерлем, җитәр,
Алай күп өзсәң,
Бар ямем бетәр.

Иртәгә бире
Чыксаң тагын да,
Бер матур чәчәк
Бирермен шунда».

Гөлнең сүзенә
Вил карышмады.
Һәм шуңа гөл дә
Яратты аны.

УРАҠ ӨСТЕНДӘ

Бөркү җәйге көн.
Ҡояш кыздыра.
Дәртле эш ҡайный
Ҡолхоз ҡырында.
    Ургыч машина
    Ҡырны гөрләтә.
    Артыннан аның
    Бәйлиләр көлтә.
Маһинур апа
Бара иң алда.
Алсу йөзеннән
Тирләре тама.
    Менә башын ул
    Ҡүтәрде кинәт:
    «Иреннәр чатный,—
    Сусадым бигрәк!»
Ишеткән аны
Ҡечкенә Лилә,
Чиләк күтәреп
Янына килә...
    Салкын су эчеп
    Баскач сусавын,
    Эшенә апа
    Тотына тагын.
Ә Лилә китә,
Ҡулында чиләк:
«Ҡем бик сусады?
Ҡемгә су кирәк?..»

КУРЧАК

Кичә Ләйлә көйсезләнеп
Атып бәрде курчагын.
Уйныйсы килгәч, ул аны
Эзли башлады тагын.

Өстәл асларын карады,
Шкаф артын капшады.
Сандык яннары калмады,
Тик курчагын тапмады.

Әнисе әйтте аңарга:
«Курчагың синнән бизгән,
Ләйлә мине гел кыйный дип,
ул чыгып киткән бездән».

ҚЫШ БАБАЙ БҮЛӘКЛӘРЕ

Матур бәйрәм җырыбыз
Яңгырагач еракка:
Кыш бабабыз ишетеп
Килде безгә кунакка.

Елмаеп ул эндәшә:
«Исәнмесез, дусларым!
Ямьле бәйрәм кичендә
Яусын сезгә котлавым.

Нинди әйбәт уйныйсыз
Яшел чыршы янында.
Бүләк биреп, мин сезне
Шатландырыйм тагын да.

Чикләвекләр җибәрде
Җитез тиен урманнан,
Баллы ап-ак күмәчләр —
Бүләк сезгә куяннан.

Дус-ишләре каршында
Калмас өчен көлкегә,
Перәннекләр, конфетлар
Төреп бирде төлке дә...

Менә тагын апельсин,
Нинди пешкән — күрегез;
Боларны соң җәнлекләр
Каян алган,— белегез»...

ЭЧТӘЛЕК

Мәктәп 3
Кечкенә агроном . . .4
Җиләк пеште 6
Минем кунагым . . .6
Чебиләр 7
Ләйсән ява 8
Без үстергән гөлләр . .9
Кыш бабай 10
Кошлар туйдырам . .11
Чаңгы шуабыз . . .12
Боекма, песием . . .13
Каз бәбкәләре 15
Ак каен 16
Бака 17
Мактанчык Ильяс . .18
Күбәләккә 18
Акбай 19
Чыпчыгым 20
Сандугач 22
Кем ялкау 23
Чыныга, имеш . . 24
Кармак салганда . 25
Безнең сыер 26
Гөл янында 27
Урак өстендә 28
Курчак 29
Кыш бабай бүләкләре .30

ИЗДАНИЕ ДЛЯ ДЕТЕЙ И ЮНОШЕСТВА

Анас Кари

ВЕСЕЛЫЕ КАПЕЛЬКИ

Стихи

(на татарском языке)

ИБ № 5700

Редакторы *З. Хөснетдинова*, Художнигы *З. Мөхәммәтҗанова*. Художество редакторы *Ф. Хәсьянова*. Техник редакторы *Г. Шәрифуллина*. Корректоры *М. Кәримова*. Җыярга тапшырылды 10.08.89. Басарга кул куелды 25.12.89. Форматы $60\times90^1/_{16}$. Офсет № 2, китап-журнал кәгазе. «Литературная» гарнитурасы. Офсет басма. Шартлы басма табагы 2,0. Шартлы буяу-оттиск 3,0. Нәшер-хисап табагы 1,35. Тиражы 30 000 экз. Заказ 3-397. Бәясе 10 тиен. Татарстан китап нәшрияты. 420084. Казан, Бауман ур., 19. Татарское книжное издательство. 420084, Казань, ул. Баумана, 19. Татарстан АССР Нәшрият, полиграфия һәм китап сәүдәсе эшләре дәүләт комитетының Камил Якуб исемендәге полиграфия комбинаты. 420084. Казан, Бауман ур., 19.



10 тиен.